

БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDR… …GAZINE
0+
Салават күпере
№12 2024
ЯҢА ЕЛ
вконтакте
RUTUBE
podpiska.pochta.ru





Влада Семёнова рәсеме

# Тыйнак Боз чанасы

Бу хәл баскыч астындагы чоланда нәкъ Яңа ел алдыннан булды.

– Кыш көне чана шуудан да рәхәте юк, – диде тәҗрибәле Чана түти. – Миңа утырып таудан төшкәндә, балаларның бәхете эчләренә сыймый!

– И-и-и, аның ни кызыгы бар инде? – дип елмайды өр-яңа Сноуборд. – Менә мин – Сноубордта йөрү шәп тә, заманча да!

– Хәзерге яшьләр берни белми инде, – дип бәхәскә кушылды апалы-сеңелле Тимераяклар. – Кышын иң яхшысы ул – бездә йөрү!

– Тик, тимераякта йөргәндә, егылуы бик җиңел, – диде Чана түтинең энесе – Тюбинг. – Ә менә мин йомшак та, уңайлы да.

– Ләкин син артык зур, – диештеләр Чаңгылар. – Ә без нечкә, җиңел һәм бик дус. Әле ярдәмчеләребез – таякларыбыз да бар!

Чоландагы бәхәстә бары тик гап-гади пластиктан ясалган кечкенә Боз чанасы гына катнашмады. Аны былтыр кыш азагында гына сатып алганнар иде. Шул вакыттан бирле Боз чанасы чолан диварындагы кадакта эленеп тора. Моннан ул чоланда яшәүчеләрнең һәркайсын күрә һәм аларның бәхәсләшүен дә бик яхшы ишетә. Тыйнак Боз чанасы эченнән аларның барысы белән дә ризалаша һәм үзе турында: «Ә минем нинди уңай якларым бар? Мин нәфисме? Әллә тәҗрибәлеме? Юк шул... Мин бит әле чын бәхетнең дә ни икәнен белмим», – дип уйлый иде.





podpiska.pochta.ru

БУ ЙОРТНЫҢ ҺӘР КАТЫНДА 4 ТӨРЛЕ ҖӘНЛЕК ЯШИ. БУШ ФАТИР ХУҖАЛАРЫН ЯБЫШТЫРГЫЧЛАР АРАСЫННАН ТАП. ИСЕҢДӘ ТОТ: ҺӘР РӘТТӘ ҺӘМ БАГАНАДА ХАЙВАННАР КАБАТЛАНЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ.



podpiska.pochta.ru

# Кышкы уен

ДУСЛАРГА ЧЫРШЫ ЯНЫНА БАРЫП ҖИТӘРГӘ ЯРДӘМ ИТ.




podpiska.pochta.ru

Фәридә Ризаева рәсемнәре

**ЧЫРШЫНЫ ДӨРЕС ИТЕП БУЯ ҺӘМ КАР БӨРТЕГЕ ЯСАЛГАН ШАРЛАР БЕЛӘН БИЗӘ. НИЧЕК УЙЛЫЙСЫҢ, БУ УЕНЧЫКЛАРНЫҢ КАЙСЫСЫ – ӘКИЯТТӘГЕ ШАР?**






**ЯБЫШТЫРГЫЧЛАР АРАСЫННАН КҮЛӘГӘГӘ ТУРЫ КИЛГӘН УЕНЧЫК РӘСЕМНӘРЕН ТАП ҺӘМ КЫШ БАБАЙНЫҢ БАЛАЛАРГА НИНДИ БҮЛӘК ӘЗЕРЛӘГӘНЕН БЕЛ.**

podpiska.pochta.ru

# Шаян елан




ВИДЕОНЫ КАРА
YOUTUBE

ВИДЕОНЫ КАРА
ВКОНТАКТЕ


ВИДЕОНЫ КАРА
RUTUBE



**КИРӘК БУЛА:**
ТӨСЛЕ КӘГАЗЬ, ҖИЛЕМ, КАЙЧЫ, ӘЗЕР ПЛАСТИК КҮЗЛӘР, ГАДИ КАРАНДАШ, СЫЗГЫЧ, КАРА МАРКЕР.

# Зәңгәрсу йолдыз






ВИДЕОНЫ КАРА
YOUTUBE

ВИДЕОНЫ КАРА
RUTUBE

ВИДЕОНЫ КАРА
ВКОНТАКТЕ

**КИРӘК БУЛА:**
ТӨСЛЕ КӘГАЗЬ, ҖИЛЕМ, КАЙЧЫ, ЭНӘ, ҖЕП, ТӨРЛЕ ЗУРЛЫКТАГЫ МӘРҖӘННӘР